# Кассирлар бетә, роботлар килә

**Яхшы, акчалы, күңел кушкан эш турында кем генә хыялланмый икән? Югары уку йортын тәмамлап, белгечлеге буенча эш таба алмаучылар хәйран күп. Гомер буе эшләгән хезмәт урынын төрле сәбәпләр аркасында югалтучылар да байтак. Шундый көнгә калмас өчен нинди һөнәр сайларга һәм бу уңайдан дәүләт нинди чаралар күрә? ТР хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры Эльмира ЗАРИПОВА белән әнә шулар хакында әңгәмә кордык.**



**– Эльмира Әмировна, ел тәмамланырга озак калмады. Хезмәт базарындагы хәлләргә нинди бәя бирәсез?**

– Республикада бу уңайдан тотрыклылык күзәтелә. Идел буе федераль округы һәм, гомумән, Россия төбәкләре белән чагыштырганда да күрсәткечләр күпкә яхшырак. Татарстанда хезмәткә яраклы яшьтәге кешеләрнең 70 проценттан артыгы эшли. Әшсезләр саны август–октябрь айларында 3,2 процентны тәшкил итте. Россиядә ул күрсәткечнең – 5,3, Идел буе төбәгендә 4,6 процент булуын беләбез. Вакансия буенча алганда, бер эшсезгә ике хезмәт урыны тәкъдим ителә. Хәзер хезмәт базарында 1980 нче еллар азагыннан соң әкренләп 1990 елларда туучылар килеп кушыла. Ә ул чакта балалар туу байтакка кимегән иде. Киләсе 5–10 ел эчендә эшче көчләргә кытлык әлеге демография мәсьәләсе белән дә аңлатылачак. Эш бирүче оешма җитәкчеләре, кадрларны әзерләүче мәгариф системасы, безнең тармак, мәшгульлек үзәкләре алга таба зур проблемалар килеп чыкмасын өчен, әзерлекле, планлы эш алып барырга тиеш.

**– Нинди чараларга аерым тукталыр идегез?**

– Татарстан икътисадын үстерү ягыннан шактый гына инвестиция программалары эшли. Президентыбыз Рөстәм Миңнеханов шундый таләп куя: кайсы гына тармакта, нинди генә җитештерүләр ачылмасын, ул бюджетка акча кертүдән тыш, шул җирлектәге халыкка эш урыны булдыруны да максат итәргә тиеш. Кемдер сәламәтлеге ягыннан, кемдер баласын яки бүтән якын кешесен карагангa эш таба алмый. Үзләренең эшләргә теләкләре зур. Андый егәрле кешеләр пенсионерлар арасында да аз түгел. Аларның һәркайсын булдыра алган һөнәренә укытып, эш табарга ярдәм итсәк, хезмәт базарындагы эшсезлекне күпмедер дәрәҗәдә киметергә дә мөмкинлек бирер иде бу Татарстанда быелның 1 ноябрь мәгълүматлары буенча, 14 мең 33 кеше эшсезлек буенча исәптә тора, вакансияләр 35 меңнән артык. Гыйнвардан башлап октябрь аена кадәр мәшгульлек үзәкләренә төрле сораулары туып 119 мең 200 кеше мөрәҗәгать иткән. Аларның 67 меңгә якыны – эш эзләүчеләр. 42 меңгә якын кеше эшкә урнаштырылган. Исәптә торучыларның 25 меңе эш тапкан.

**– Бер эшсезгә ике эш урыны тәкъдим ителә, дидегез. Бу хакта байтактан ишетәбез. Ник ул эш урыннары һаман да буш?**

– Гаҗәпләнерлек нәрсә күрмим. Күп вакыт оешма җитәкчесен эш сорап килүченең сәләте, белеме канәгатьләндерми. Яхшы белгечләргә кытлык бар, алар, кем әйтмешли, аунап ятмый. Киресенчә дә була: хезмәткәр үзе сайлана. Бу хезмәт хакы, яшәү урынына да бәйле булырга мөмкин. Мәсәлән, Түбән Камада заводлар күп, анда кирәкле белгечнең Ютазы районында яшәве ихтимал. Күчеп килсә, аны дүрт куллап эшкә алырга әзерләр. Икенче ягын онытмыйк: озак еллар бер урында гомер кичергән кешегә яшәү урынын алыштыру җиңел түгел. Түбән Камадагыдан кайтышрак булса да, ул эшне шул җирлектән эзли. Яшьләр күчеп йөрүгә каршы түгел, чөнки гаиләгә берекмәгәннәр, калдырыр, алыштырыр милекләре юк. Бер четерекле ягы бар: яшьләрнең кулында дипломы, белеме булса да, тәҗрибәләре аз. Игътибарга алсак: мәшгульлек үзәкләрендә эшсезлек буенча исәптә торучыларның байтагы урта буын, пенсия яшенә якынлашып килүчеләр һәм инде лаеклы ялга чыккан кешеләр.

**– Буш хезмәт урыннарының шактые Казан кебек зур шәһәрләргә туры киләме?**

– Әйе, Казан, Чаллы, Түбән Кама... Балык Бистәсе, Алексеевск кебек нигездә авыл хуҗалыгы белән шөгыльләнүче районнарда, Кама Аланы, Яшел Үзән кебек моношәһәрләрдә хезмәт урыны азрак. Район җитәкчеләре мөмкин булганча төрле инвестиция проектларын җәлеп итү ягын каралрга тиеш. Ул районнарда эшсезлек уртача республика дәрәҗәсе белән чагыштырганда югарырак. Казан кебек зур шәһәрләрдә, теләге булган кешегә, эш табу күпкә ансатрак. Район, авыл халкын шәһәргә китереп, бүтән һөнәргә укыту, яңа белгечлек бирү кыенрак. Шәһәргә кузгалу түгел, күрше районга барып йөрүне дә күз алдына китерә алмыйлар. Безнең менталитет шундыйрак.

**– Республикада кадрларны һөнәргә әзерләү буенча нинди программалар эшли?**

– Байтак предприятиеләр яңарды, җиһазларга баеды. Бу исә заманча җиһазларда эшли белүче яңа кадрлар таләп итә. Ул белгечләрне тиз арада әзерләү бурычы килеп басты. Республика җитәкчелеге белгечләрне читтән бик сирәк очракта гына җәлеп итү ягында. Кадрларны бюджет хисабына нигездә үзебездә әзерлибез: укытабыз, яңа технологияләргә өйрәтәбез. Бу программа 2011 елдан гамәлдә. Шул вакыт эчендә 40 оешмадан 16 мең кеше, укып чыгып, яңа һөнәрле булды. Икенче юнәлеш: ниндидер сәбәпләр аркасында эшсез калганнарны яңа һөнәрле итү, аларның осталыкларын үстерү. Әйтик, берәр структурада эшләүче белгечкә, кыскартылуга эләгеп, эшсез калу куркынычы яный, ди. Оешмага ул белгечлек урынына бүтәне кирәк. Эшсез калучыны, урамга чыгарып җибәрмичә, ихтыяҗ булган һөнәргә әзерлибез. Моның өчен аны кыска вакытлы курсларда укыту да җитә. Физик мөмкинлеге чикле кешеләр арасында да шул программалар кысасында эшле булучылар байтак. Хатын-кыз декрет ялыннан соң, өч елдан эшкә чыгарга җыена. Ярый ла, элекке хезмәт урынында көтеп торсалар... Өч яшькә кадәр баласы булган әлеге ханымнарны да махсус программа нигезендә яңа һөнәргә укытабыз. Өстәмә белем алу курслары тәкъдим ителә.

> ***Казан кебек зур шәһәрләрдә, теләге булган кешегә, эш табу күпкә ансатрак. Район, авыл халкын шәһәргә китереп, бүтән һөнәргә укыту, яңа белгечлек бирү кыенрак***

**– Өендә кечкенә бәбие булган ул хатын-кызлар нинди һөнәрләр үзләштерә?**

– Әлеге программа шулай ук 2011 елдан гамәлдә. Мәшгульлек үзәкләренә мөрәҗәгать иткән 7 меңгә якын хатын-кыз укып чыкты. Чәчтараш, маникюр остасы, пешекче, хисапчы, ландшафт һәм компьютер дизайны, төрле тармаклар, шул исәптән туризм буенча менеджер һөнәрләре популяр. Авыл районнарында туризм белән кызыксыну артты. Шул ук Яшел Үзәнне, Алабуганы уңай яктан телгә алабыз. Туризм секторы үзенә башка тармакларны да җәлеп итә: ресторан бизнесы, транспорт, товар ташу һәм башкалар.

**– Кризиска каршы күрелгән чаралар эшсезлекне киметә алдымы?**

– Әлбәттә. Узган ел да, быел да моның буенча актив чаралар күрелде. Берничәсе аеруча әһәмиятkә ия. Беренчесе – оешма эшчеләрен кирәкле һөнәргә укыту. Моның буенча оешмаларның әзер үз программалары бар. Автомобиль сәнәгатеннән “КамАЗ”, “Автотехник” предприятиеләре, җиңел сәнәгатьтән – “Кукмара”, “Адонис” тегү фабрикалары, “Агат”, “Милена” берләшмәләре шул эшчәнлеккә килеп кушылды. Гомумән алганда, 20дән артык предприятие әлеге программада катнашты. Һөнәри белем бирүче уку йортларын, курсларны тәмамлап чыгучыларны эшкә урнаштыру буенча да республикада конкрет эшләр алып барыла. Кимендә 110 мең укучыны эшле итү бурычы куелган иде. Заводларга, берләшмәләргә, килешү нигезендә, 205 егет-кыз даими эшкә урнаштырылды. Программаның тагын бер яңа юнәлеше: физик мөмкинлекләре чикле кешеләрне эшле итә алдык. Сәламәтлеге мөмкинлек биргән инвалидлар арасында да эшләргә теләүчеләр байтак. Кризиска каршы программа кысасында бу җәһәттән дә акча бүленде. Эш бирүчеләр алар өчен уңайлы мохит тудыра, эшкә өйрәтә, моның өчен аерым кеше билгелиләр, хезмәт хакы түлиләр. Чыгымнар өчен, әйткәнемчә, бюджет акчасы кучерелә, ягъни оешмаларга компенсация бирелә.

**– Мәшгульлек үзәкләрендә эшсезлек буенча кайсы белгечләр күбрәк исәптә тора?**

– Машина йөртүчеләр, эшчеләр, сатучылар, җыештыручылар, слесарь-техниклар, вахтерлар, пешекчеләр, электрон хисаплау машинасы операторлары, йөк ташучылар. Бу өлкәләрдә тотрыклылык юк, хезмәткәрләрнең берсе китә, алмашка икенчесе килә.

**– Республикада уртача хезмәт хакы күпме? Акчаны “конверт”та бирүчеләргә каршы көрәш ничек алып барыла?**

– Ул бездә 29 мең 741 сум. Узган ел белән чагыштырганда 7,5 процентка үсте. Бу яктан без Идел буе округында лидерлар рәтендә. Тик бөтен тармакта да хезмәт хакы бертөрле түгел. Җир асты казылма байлыклары чыгару, финанс өлкәләрендә хезмәт куючыларның хезмәт хакы уртачадан артып китә. Энергия, газ, су җитештерү һәм бүлү тармакларында, коммуналь һәм социаль сфераларда эшләүчеләрнең дә хезмәт хакы югары. Түләү минималь хезмәт хакыннан ким булмаска тиеш. Ул – Россиядә 7 мең 500 сум. Шуннан азрак түләгән оешма күзәтчелек органнары игътибарына эләгә. Чөнки аз керемле кеше пособие сорап, социаль органнарга килә. Ул оешмалар белән эшлибез. Нәтиҗәсе дә бар. “Конверт”та түләүгә килгәндә, узган ел “соры” хезмәт базарында 112 мең килешү “тартып чыгардык”, аларны рәсмиләштердек. Быел шундый 84 мең килешү тәэздек. Моның белән махсус комиссия шөгыльләнә. Ул ничек эшләнә? “Конверт”та хезмәт хакы алучыны бу канәгатьләндерә алмый һәм ул социаль органнарга мөрәҗәгать итә. Килешүне рәсмиләштергәч, аны берничә айдан юкка чыгаручы җитәкчеләр дә очрый. Салым органнары, Пенсия фонды кертемнәрне вакытында күчерүне күзәтеп тора. Кадрлары еш алмашынып торучы кечерәк сәүдә, көнкүреш хезмәте тармакларында да шундый бәхәсле очраклар килеп чыга. Аларны җәзага тартырга бөтен мөмкинлекләребез бар, закон безнең якта. Зур күләмдә штрафлар салына. Хезмәт хакы тоткарланган очракта да урыннарда комиссияләр эшли, кайчакта бу эшкә прокурорлар, салым органнары да кушылып китә. Килешүләр җирле бюджетка миллиард сумнар кертте. Ул акча социаль оешмаларга китә. Бүген кеше бик актив: түләү дөрес башкарылмаса, “Халык контроле”нә чыга, “кайнар линия”гә шалтырата. Аны киләчәктә күпме пенсия алачагы кызыксындыра. Пенсия буенча законнар катгыйланды. Минималь пенсия алыр өчен 30 ел стаж кирәк. Шәхси оешмада эшлисеңме, әллә дәүләт структурасындамы, Пенсия фондына ай саен кертем күчереп барылырга тиеш.

**– Киләчәктә кайсы белгечләргә кытлык булачак, кайсылары юкка чыгачак?**

– Һәр министрлык кайсы белгеч күпме кирәк булачагын мәгариф оешмаларына хәбәр итәчәк. Әйтик, күпме төзүче, пешекче, укытучы, шәфкать туташы... Байтак кына һөнәрләр берәм-берәм юкка чыгачак. Кибетләрдә кассирлар кимеячәк. Хәзер үк кайбер сәүдә нокталарында тауарны аласың да, карточка ярдәмендә акча күчереп, чыгып китәсең. Күп җирдә банк операторларының кирәге калмады, банкоматларны файдаланабыз. Хәзер кеше онлайн түләүгә күчеп бара. Хисапчылар да азаячак. Кибетләрдә товар тәкъдим итүне роботларга тапшырачаклар. Яшь буын кайсы гына өлкәдә эшләсә дә, айти программаларны аңларга тиеш. Бу карьера үсеше өчен дә мөһим. Эшче һөнәрләре – арматурачы, бетончы, газ, электр белән эретеп ябыштыручы, инженерлар һәрвакыт кирәк булачак.

**Әңгәмәдәш –**
**Фәния АРСЛАНОВА**